ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.11. 2019 ел Баулы шәһәре № 311

2020 елга Баулы муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы, «Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 2 июлендәге 546 номерлы карары, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасының Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2020 елга расларга (кушымта итеп бирелә):

Баулы муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны карау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар (1нче кушымта);

Баулы муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны караган өчен ата-аналар түләве күләме (2нче кушымта);

2020 елның 1 гыйнварына кадәр мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган мәгариф оешмаларына кертелгән балаларны караган

өчен ата-ана түләвенә кучү чорына карата төгәллек кертү коэффициентлары кулланылган мәгариф оешмалары исемлеге (кушымта №3);

2020 елның 1 гыйнварына кадәр мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына кертелгән баланы караган өчен ата-ана түләвенең кучү чорына карата төзәтү коэффициенты: 2 айдан 3 яшькә кадәрге балалар өчен - 0,87гә, 3 яшьтән алып белем бирү мөнәсәбәтләре тәмамланганчы - 0,89.

2. Баулы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына мәктәпкәчә белем бирү программаларын мәгариф оешмаларын финанслау нормативлары нигезендә гамәлгә ашыручы, әлеге карарның 1нче пункты белән расланган мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы И.И. Хөснуллина